СОВЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески,
Арский муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Тукай урамы, 2 йорт, Түбән Мәтәскә авылы,
Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы КАРАРЫ**

**27 октябрь 2025 ел** **N7**

**Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Мөндеш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

"Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Арча муниципаль районының Иске Кырлай авыл җирлеге Уставының 25 статьясы, Арча муниципаль районының Иске Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы **КАРАР ЧЫГАРДЫ**:

1. Мөндеш авылы, Татарстан урамы, 46 йорт, Мөндеш КФҮ адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2025 елның 20 ноябренә 09 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Мөндеш авылы, Татарстан урамы, 46 йорт, Мөндеш КФҮ адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2025 елның 20 ноябренә 10 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Халык исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

1 нче этап: Яшьләр, Чишмә, Җиңү урамы халкы

2 нче этап: Татарстан урамы халкы.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

Сез 2026 елда Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең Мөндеш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум, көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 75 яшьтән узган гражданнардан 150 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, шулай ук махсус хәрби операциядә

катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, ире яки хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итәргә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юл-урам челтәренә нигез салу һәм вак таш белән каплау Мөндеш авылы Татарстан урамы, Чишмә урамы)?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

5. Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Мөндеш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына: ТР, Арча районы, Мөндеш авылы, Татарстан урамы, 46 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Лутфуллин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН · АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН · МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «СТАРОКЫРЛАЙСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» · ОГРН1121690069209
СОВЕТ СТАРОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН1609012660